**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2025 Балык Бистәсе штп. № 52пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 13.01.2025 №03пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2019 - 2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү" дәүләт программасын раслау турында” 05.03.2019 №158 карарын гамәлгә ашыру максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» 13.01.2025 №03пи карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Роспотребнадзор Идарәсенең Лаеш, Питрәч, Балык Бистәсе районнары территориаль бүлегенә мәгариф оешмалары тарафыннан көндез була торган лагерьлар сменаларын, мәгариф оешмалары тарафыннан көндез була торган хезмәт һәм ял лагерьлары сменаларын эксплуатацияләү буенча профилактик чараларны «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248-ФЗ Федераль законы таләпләренә туры китереп уздыруны тәкъдим итәргә; «Иҗади сәләтле яки социаль актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре тәрбияләнүчеләре өчен палаткалы лагерьларда сменалар» таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма
комитетының 12.03.2025
№52пи карары белән
расланган

**ИҖАДИ СӘЛӘТЛЕ ЯКИ СОЦИАЛЬ АКТИВ БАЛАЛАР ҺӘМ ВОЛОНТЕРЛАР, БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘР ИҖТИМАГЫЙ БЕРЛӘШМӘЛӘРЕ АКТИВЫ ӘГЪЗАЛАРЫ, БАЛАЛАРГА ӨСТӘМӘ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ ТӘРБИЯЛӘНҮЧЕЛӘРЕ ӨЧЕН ПАЛАТКАЛЫ ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР (2025 ЕЛ)**
**14047,36 СУМ (ШУЛ ИСӘПТӘН БЮДЖЕТ 1196,26 СУМ, ТУГАН. КЕРТЕМ 211,10 СУМ.)**

| Палаткалы лагерь исеме (оештыручы) | Уздыру территориясе | Кеше саны* | Көннәр саны* | Юлламаның норматив бәясе 11550,49 | Бюджет-тан субсидия-ләр 9817,92 | Ата-ана взносы ** 2000,00 | Башка средстволар (предприятие, җирле бюджет) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| "Өмет»спорт-сәламәтләндерү лагере | ТР Балык Бистәсе муниципаль районы | 160 | 7 | 1848078,40 | 1570867,20 | 320000,00 | |
| Барлыгы | | 160 | 7 | 1848078,40 | 1570867,20 | 320000,00 | |